РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.11.2020 № 954

Нурлат муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 2021 елга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 ел, 14 декабрь, 854 нче карары һәм Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга:

- Нурлат муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә бирелә торган норматив чыгымнарны;

- балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 процент күләмендә төзәтү коэффициентын расларга.

2. «Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 18.11.2020 ел,
№ 954 карары белән расланды

Нурлат муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Урнашу урыны | Норматив чыгымнар (бер елга 1 укучыга исәпләнгән сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өчъеллык уку вакыты | дүртъеллык уку вакыты | бишьеллык уку вакыты | җидееллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җире | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыка сәнгате | авыл җире | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җире | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җире | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Бию сәнгате | шәһәр җире | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Бию сәнгате | авыл җире | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җире | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җире | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җире | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җире | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җире | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җире | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җире | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җире | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |